| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.12.2014 № 696

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 23 декабрендә теркәлгән, №2606

2015 елда вакытлыча эшкә урнашулары чорында балигъ булмаган һәм эшсез гражданнарга матди ярдәм күләмнәре турында

“2014–2020 елларга Татарстан Республикасында яшәүчеләргә эшкә урнашуга ярдәм итү” дәүләт программасын раслау турында” 09.08.2013 ел, №553 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, боерык бирәм:

2015 елга матди ярдәм күләмнәрен билгеләргә:

вакытлыча эшкә урнашулары чорына 14 тән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга – аена бер кешегә эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 1,5 тапкырга тигез булган суммасында;

түләнүле иҗтимагый эшләрдә катнашучы эшсез гражданнарга – аена бер кешегә эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 2,5 тапкырга тигез булган суммасында;

вакытлыча эшкә урнашулары чорына, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарга – аена бер кешегә эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 2,5 тапкырга тигез булган суммасында;

вакытлыча эшкә урнашулары чорына, урта һөнәри белемгә ия булучы һәм тәүге тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарга аена бер кешегә эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 2,5 тапкырга тигез булган суммасында;

вакытлыча эшкә урнашулары чорына, гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлаган, тәүге тапкыр эш эзләүчеләр арасыннан эшсез гражданнарга – аена бер кешегә эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 2,5 тапкырга тигез булган суммасында.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**